КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 апрель г.Казань № 248

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 май, 381 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 май, 381 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 ноябрь, 880 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (кире кайтаруга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр, чаралар) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр чаралар оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (кире кайтару) максатларында бирелә.»;

5 пунктта:

дүртенче һәм бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«корылмаларга хезмәт күрсәтүләргә (аренда, коммуналь һәм эксплуатация чыгымнары, техник хезмәт күрсәтү, модернизация, реновация, объектларны әзерләү) түләү, вакытлыча корылмаларны, бүлмәләрне, мәйданнарны, футбол кырларын, транспортны кертеп;

чараны тормышка ашыру өчен кирәкле техник чараларны һәм ярдәмче җайланмаларны арендалау, сатып алу, шулай ук аларны монтажлау, демонтажлау, эшләтеп җибәрү-көйләү һәм хезмәт күрсәтү»;

җиденче һәм сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«спорт командаларын, Татарстан Республикасы делегацияләрен төрле спорт һәм яшьләр чараларында катнашу өчен командировкалау, чараларда катнашучыларның, бөтенроссия һәм халыкара иҗтимагый оешмалары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең, чара регламенты буенча катнашулары мәҗбүри булган техник белгечләрнең яшәве, туклануы, тәүлеклек акчасы һәм юл йөрүе;

спортчылар – спорт төрләре буенча Татарстан Республикасы җыелма командалары әгъзалары, тренерлар, хөкемдарлар һәм белегечләр һәм чара регламенты буенча катнашулары мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүче персоналга кирәкле спорт инвентаре сатып алу;»;

тугызынчы абзацка «(хезмәт буенча һәм эшлекле сәфәрләрне оештыруга чыгымнарны кертеп)» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бүлмәләрне, транспорт чараларын, мәйданнарны, корылмаларны, вакытлыча булганнарын да кертеп, чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле төрле төрдәге корылмаларны, аларны монтажлау һәм демонтажлауны кертеп, бизәү;»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бүләкләү атрибутикасын, сувенир продукцияне әзерләү җһәм сатып алу;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«программа белән һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү, IT-технологияләр (электрон хөкемдарлык, электр челтәре инфраструктурасы белән җиһазлау/җиһазлап бетерү, теле- һәм интернет тапшыруларны оештыру);»;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чарада катнашучыларны чара вакытында килеп чыккан бәхетсез очраклардан иминиятләү (дәвалауның һәм тернәкләнерүнең барлык этапларындагы чыгымнарны иминият түләүләре исәбеннән кайтаруны исәпкә алып), чара регламенты буенча мәҗбүри булган оештыручының җаваплылыгын иминиятләү, мөлкәтне иминиятләү;»;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«элемтә, радиоэлемтә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре хезмәтләре, лингвистик хезмәтләр, почта чыгымнары;»;

егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән турыдан-туры бәйле оештыру кертемнәре, үткәрүче оешманың регламентлаучы документлары нигезендә акчалата бүләкләрне түләү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«җир кишәрлекләре арендасы өчен түләү;

физик культура һәм спорт буенча белгечләрнең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү курсларын оештыру һәм үткәрү;

чараларны флористик бизәү, беркетмәсен алып бару өчен түләү;

билет һәм тамашачы программаларын оештыру (билетлар әзерләү, бастыру һәм тарату, ярышлар үткәрү урыннарында тамашачылар билетлар буенча керү системасын оештыру һәм техник озата бару, үткәрү урыннарында тамашачы урыннарына саннар әзерләү (булмаган очракта), үткәрү урыннарында саклау камералары эшен оештыру, ярышлар үткәрү урыннарында билет кассасы эшен оештыру, тамашачылар өчен мәгълүмат алу урыннары эшен оештыру, җанатарлар атрибутикасын сатып алу һәм тарату).»;

6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чараларны оештыруны, үткәрүне һәм аларда катнашуны гамәлгә ашыру;»;

7 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик зат җитәкчесе раслаган һәм Министрлык белән килештерелгән чараларны оештыруга, үткәрүгә һәм аларда катнашуга чыгымнар сметасын, үз эченә аларның күләмен һәм алу чыганагын нигезләүче мәгълүматны күрсәткән чыгымнар юнәлеше калькуляциясен алган финанс-икътисадый нигезләүне теркәп (чараларны оештыруга, үткәрүгә һәм аларда катнашуга гамәлдә башкарылган чыгымнарны, аларның күләмен нигезләп раслый торган документлар (счетлар, счет-фактуралар, товар-транспорт накладнойлары, түләү йөкләмәләре, башкарылган эшләрне кабул итү актлары)).»;

13 пунктның өченче абзацында «чараларны үткәрү белән бәйле» сүзләрен «чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «чараларны үткәрү белән бәйле чыгымнар» сүзләрен «юридик затларның чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Юридик затларның чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарын кайтаруга субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + ... + З_n,$$

монда:

С – субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме;

$З_1$, $З_2$, $З_3$, ..., $З_n$ – әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча, охшаш (бер төрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турында мәгълүматны, шул исәптән оештыручылар-әзерләүчеләр бәяләре хакында, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта, җитештерүчеләрнең һәм сатучыларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп, анализлаудан гыйбарәт базар бәяләрен чагыштыру ысулы (базарны анализлау) белән билгеләнә торган чыгымнар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин